КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 17 август г.Казань № 688

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 ел, 20 май, ТРЗ-26 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2012 ел, 24 сентябрь, 798 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 ел, 20 май, ТРЗ-26 нчы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру чаралары хакында» 2012 ел, 24 сентябрь, 798 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 февраль, 66 нчы; 2015 ел, 12 сентябрь, 670 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1101 нче, 2019 ел, 15 май, 393 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча республика комиссиясе турында нигезләмәдә:

түбәндәге эчтәлекле 1.6 пункт өстәргә:

«1.6. Республика комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү мәсьәләләренә түбәндәгеләр карый:

Республика комиссиясенең утырышларын һәм башка план чараларын әзерләү һәм үткәрүне оештыру;

Республика комиссиясе утырышларында карау өчен материалларны үз вакытында әзерләүне һәм тапшыруны тикшереп торуны гамәлгә ашыру;

Республика комиссиясенең эш башкаруны алып бару;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре вәкилләренә, шулай ук Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының башка территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм Республика комиссиясе утырышына материаллар әзерләүдә катнашучы оешмалар вәкилләренә, тиешле сорату кергәндә, консультатив ярдәм күрсәтү;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау буенча ведомствоара чараларны, шул исәптән ведомствоара конференцияләр, киңәшмәләр, семинарларны оештыруда катнашу;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау мәсьәләләре буенча алар үткәргән тикшерүләрдә, киңәшмәләрдә, семинарларда, коллегияләрдә, конференцияләрдә һәм башка чараларда катнашу;

комиссиягә кергән балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләренең хәбәрләрен, гражданнар мөрәҗәгатьләрен Республика комиссиясе тарафыннан карауны оештыру;

Республика комиссиясе алдында торган бурычларны хәл итү өчен кирәкле мәгълүматны җыю, эшкәртү һәм гомумиләштерү;

«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 5 статьясында каралган затлар саны турында мәгълүмат җыю һәм гомумиләштерү, аларга карата балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре тарафыннан индивидуаль профилактик эш алып барыла;

ситуацияне анализлау максатында Республика комиссиясе каравына тапшыру өчен балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеге, хокук бозулары, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау турында мәгълүматларны гомумиләштерү;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау мәсьәләләре буенча мәгълүмати һәм аналитик материаллар әзерләү;

Республика комиссиясе алдында торган бурычларны хәл итү өчен эксперт төркемнәре, штаблар, шулай ук консилиумнар һәм башка киңәшмә органнары эшен Республика комиссиясе рәисе кушуы буенча оештыру;

Республика комиссиясе алдында торган бурычларны хәл итү өчен федераль дәүләт органнары, федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка берләшмәләр, оешмалар белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

федераль дәүләт органнарына, федераль дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга, муниципаль комиссияләргә Республика комиссиясе утырышында аның компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карау өчен кирәкле материалларны (мәгълүмат) тапшыру турында соратуларны җибәрү;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге публикацияләр һәм чыгышлар әзерләүдә катнашу юлы белән Республика комиссиясе эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү, аларны чишү балигъ булмаганнарның, аларның ата-аналарының һәм башка законлы вәкилләренең закон белән саклана торган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен боза торган белешмәләрне публикацияләрдә һәм чыгышларында кулланмыйча гына, аларны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгару һәм чыгыш ясауда катнашу юлы белән;

муниципаль комиссияләр эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә анализ үткәрү;

муниципаль комиссияләрдән кергән Республика комиссиясе йөкләмәләрен үтәү турында мәгълүматны анализлау һәм (яисә) гомумиләштерү;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча Республика комиссиясенә тиешле проектлар кергәндә норматив хокукый актлар проектларына бәяләмәләр әзерләүдә катнашу;

Республика комиссиясе тарафыннан Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча республика комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү кысаларында башка вәкаләтләрне үтәү.»;

2.2 – 2.5 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Республика комиссиясе рәисе әлеге Нигезләмәнең 2.5 пунктындагы «а» – «д« һәм «ж» пунктчаларында, шулай ук комиссия әгъзасының вәкаләтләрен гамәлгә ашыра:

а) Республика комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә;

б) Республика комиссиясе утырышында рәислек итә һәм аның эшен оештыра;

в) Республика комиссиясе утырышында тавыш биргәндә хәлиткеч тавыш бирергә хокуклы;

г) дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда Республика комиссиясен тәкъдим итә;

д) Республика комиссиясе утырышының көн тәртибен раслый;

е) Республика комиссиясе утырышы датасын билгели;

ж) Республика комиссиясе рәисе урынбасарына, Республика комиссиясе җаваплы секретаренә, Республика комиссиясе әгъзаларына Республика комиссиясе компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча мәҗбүри йөкләмәләр бирә;

з) вәкаләтле органнарга (вазыйфаи затларга) Республика комиссиясенең персональ составын формалаштыру буенча тәкъдимнәр тапшыра;

и) Республика комиссиясенең эш планы үтәлешен контрольдә тота, Республика комиссиясе карарларына кул куя;

к) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау эше турында Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә хисаплылыкны тәэмин итә.

2.3. Республика комиссиясе рәисе урынбасары әлеге Нигезләмәнең 2.5 пунктындагы «а»– «д» һәм «ж» пунктчаларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра, шулай ук:

а) Республика комиссиясе рәисе йөкләмәләрен үти;

б) Республика комиссиясе рәисе булмаганда аның вазыйфаларын башкара;

в) Республика комиссиясе карарлары үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итә;

г) Республика комиссиясе утырышында карау өчен материалларны үз вакытында әзерләүне контрольдә тота.

2.4. Республика комиссиясенең җаваплы секретаре әлеге Нигезләмәнең 2.5 пунктындагы «а», «в»– «д» һәм «ж» пунктчаларында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыра, шулай ук:

а) Республика комиссиясе утырышында карау өчен материаллар әзерләүне гамәлгә ашыра;

б) Республика комиссиясе рәисе һәм рәисе урынбасары йөкләмәләрен үти;

в) комиссия әгъзаларын һәм Республика комиссиясе утырышында катнашучы затларны утырыш вакыты һәм урыны турында хәбәр итә, аларның килү-килүләрен тикшерә, Республика комиссиясе каравына чыгарылган мәсьәләләр буенча материаллар белән таныштыра;

г) утырышта тиешле мәсьәләне карау нәтиҗәләре буенча Республика комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарлар проектларын әзерләүне һәм рәсмиләштерүне гамәлгә ашыра;

д) Республика комиссиясе карарлары күчермәләрен тапшыруны тәэмин итә.

2.5. Республика комиссиясе әгъзалары Республика комиссиясе компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне (эшләрне) караганда һәм тикшергәндә тигез хокукларга ия һәм түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар:

а) аны әзерләү буенча Республика комиссиясе утырышында катнашалар;

б) алдан (Республика комиссиясе утырышына кадәр) аны карап тикшерү өчен чыгарылган мәсьәләләр буенча материаллар белән танышалар;

в) мәсьәләне (эшне) тикшерүне кичектерү һәм аның буенча өстәмә материаллар соратып алу турында тәкъдимнәр кертәләр;

г) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау эшен камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын булдырмау сәбәпләрен һәм шартларын ачыклау һәм бетерү буенча тәкъдимнәр кертәләр;

д) карала торган мәсьәләләр (эшләр) буенча Республика комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарлар турында фикер алышуда катнашалар һәм аларны кабул иткәндә тавыш бирәләр;

е) Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда һәм тәртиптә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзиләр;

ж) балигъ булмаганнарның мәгариф, хезмәт, ял, сәламәтлек саклау һәм медицина ярдәме, торак һәм башка хокукларын гамәлгә ашыруны тәэмин итүче, республика комиссиясенә балигъ булмаганнарның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре бозылу, аларның тормышына һәм сәламәтлегенә карата янаулар булу турында, балигъ булмаганнар белән көч куллану очракларына һәм җәбер-золымның башка рәвешләренә кагылышлы хәбәрләрне тикшерү максатларында, шулай ук балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга, аларның күзәтүчесезлегенә һәм хокук бозулар кылуга ярдәм итүче сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау максатларында;

з) Республика комиссиясе рәисе йөкләмәләрен үтиләр;

и) Республика комиссиясе рәисенә утырышта катнашуы яки утырышта булмау сәбәпләре турында хәбәр итәләр.»;

2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Республика комиссиясенең эш планы проектына тәкъдимнәр Республика комиссиясенә аның әгъзалары тарафыннан Республика комиссиясе рәисе яисә Республика комиссиясе карары белән билгеләнгән срокларда язма рәвештә кертелә.

Республика комиссиясе утырышында мәсьәләләрне карау буенча түбәндәге тәкъдимнәр булырга тиеш:

а) мәсьәләнең исеме һәм аны Республика комиссиясе утырышында карау кирәклеген кыскача нигезләү;

б) мәсьәләне әзерләү өчен җаваплы Республика комиссиясе органы (оешмасы), һәм (яки) вазыйфаи зат турында мәгълүмат;

в) бергә үтәүчеләр исемлеге (алар булганда);

г) Республика комиссиясе утырышында карау срогы.

Республика комиссиясенең эш планы проектына тәкъдимнәр алдан килештерү өчен Республика комиссиясе әгъзаларына җибәрелә ала.

Республика комиссиясенең эш планы проекты Республика комиссиясенә кергән тәкъдимнәр нигезендә төзелә, Республика комиссиясе рәисе белән килешенеп, утырышта фикер алышу һәм раслау өчен Республика комиссиясенең эш планын гамәлгә ашыру елына кадәр ел ахырында чыгарыла.

Республика комиссиясенең эш планына үзгәрешләр аның составына керүче затларның тәкъдимнәре нигезендә Республика комиссиясе утырышында кертелә.

Республика комиссиясе әгъзалары, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләренең, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча башка территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның вазыйфаи затлары, алар Республика комиссиясенең эш планын үтәү йөзеннән Республика комиссиясе утырышларында карау өчен тиешле мәгълүмати материаллар әзерләү йөкләнгән.

Республика комиссиясе утырышы көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар республика комиссиясенә органнар (оешмалар), вазыйфаи затлар, республика комиссиясе әгъзалары тарафыннан, аларны әзерләү өчен җаваплы республика комиссиясенең эш планы нигезендә, утырыш уздырылган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча тапшырыла һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

а) карауга чыгарылган мәсьәлә буенча белешмә-аналитик мәгълүмат;

б) карала торган мәсьәлә буенча Республика комиссиясе карары проектына тәкъдимнәр;

в) тәкъдим ителгән Республика комиссиясе карары проекты буенча аерым фикерләр (булганда);

г) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының кызыксынучы органнары һәм учреждениеләре, башка дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары белән Республика комиссиясе карары проектын килештерү материаллары;

д) мәсьәләне карау өчен кирәкле башка мәгълүматлар.

Материалларны әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән срокта тапшырмаган яки әлеге материалларга карата таләпләрне бозып тапшырган очракта, мәсьәлә карап тикшерүдән төшереп калдырылырга яки Республика комиссиясе рәисе карары буенча икенче утырышка күчерелергә мөмкин.

Утырышның көн тәртибе, утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча карарлар проектлары һәм әлеге мәсьәләләр буенча тиешле материаллар Республика комиссиясе әгъзаларына утырыш уздырылган көнгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Республика комиссиясе әгъзалары һәм утырышның көн тәртибе, карар проекты һәм башка материаллар җибәрелгән, искәрмәләр һәм тәкъдимнәр булган очракта, аларны утырыш башланганчы Республика комиссиясенә тапшыралар.

Республика комиссиясе утырышының датасы, вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында Татарстан Республикасы прокуроры хәбәр итә.»;

2.10 пунктта «, шулай ук кирәк булганда» сүзләрен төшереп калдырырга;

2.13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Республика комиссиясе рәисе тарафыннан игълан ителгән тавыш бирү нәтиҗәләре Республика комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелә.»;

2.14 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Республика комиссиясе утырышы беркетмәсендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Республика комиссиясенең исеме;

б) утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

в) утырышта катнашучылар һәм Республика комиссиясенең булмаган әгъзалары, утырышта катнашучы башка затлар турында белешмәләр;

г) көн тәртибе;

д) коллегиаль орган утырышын документлаштыру ысулы турында билге (стенография, видеоконференция, диктофонга язылу һ. б.);

е) Республика комиссиясе утырышында каралган мәсьәләләрнең исеме һәм аларны тикшерү барышы;

ж) Республика комиссиясе утырышында карала торган мәсьәләләр буенча тавыш бирү нәтиҗәләре;

з) карала торган мәсьәлә буенча кабул ителгән карар.

Республика комиссиясе утырышы беркетмәсенә Республика комиссиясе утырышында каралган мәсьәләләр буенча докладлар материаллары, белешмә-аналитик һәм башка мәгълүмат (булганда) теркәлә.»;

2.15.1 пунктының бишенче абзацында «ата-анасы исеме» сүзләреннән соң «(соңгысы – булган очракта)» сүзләрен өстәргә;

Татарстан Республикасында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча муниципаль комиссияләр турында күрсәтелгән карар белән расланган нигезләмәдә:

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Муниципаль районда бер муниципаль комиссия барлыкка килә. Шәһәр округында, кагыйдә буларак, бер муниципаль комиссия барлыкка килә. Шәһәр округында башкарыла торган эш күләмен исәпкә алып, шәһәрнең административ-территориаль бүленеше нигезендә берничә муниципаль комиссия төзелергә мөмкин.»;

2.7 пунктта:

икенче абзацта «функцияләр» сүзен «вәкаләтләр» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«алар муниципаль комиссия рәисенә утырышта катнашуы яки утырышта булмау сәбәпләре турында хәбәр итәләр.»;

2.9 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Шәһәр округында төзелгән муниципаль комиссияләрнең функцияләрен үтәү федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җирле үзидарәнең вәкиллекле органы тарафыннан билгеләнә.»;

түбәндәге эчтәлекле 2.9[1] пункт өстәргә:

«2.9[1]. Муниципаль комиссияләр эшчәнлеген тәэмин итү мәсьәләләренә түбәндәгеләр керә:

муниципаль комиссиянең утырышларын һәм башка план чараларын әзерләү һәм үткәрүне оештыру;

муниципаль комиссия утырышларында карау өчен материалларны үз вакытында әзерләүне һәм тапшыруны контрольдә тотуны гамәлгә ашыру;

муниципаль комиссиянең эш башкаруын алып бару;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре вәкилләренә, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының башка территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары һәм муниципаль комиссия утырышына материаллар әзерләүдә катнашучы оешмалар вәкилләренә, тиешле запрос кергәндә, консультатив ярдәм күрсәтү;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау буенча ведомствоара чараларны, шул исәптән ведомствоара конференцияләр, киңәшмәләр, семинарларны оештыруда катнашу;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау мәсьәләләре буенча алар үткәргән тикшерүләрдә, киңәшмәләрдә, семинарларда, коллегияләрдә, конференцияләрдә һәм башка чараларда катнашу;

компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре тарафыннан комиссиягә кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен, хәбәрләрен муниципаль комиссия тарафыннан карауны оештыру;

муниципаль комиссия алдында торган бурычларны хәл итү өчен кирәкле мәгълүматны җыю, эшкәртү һәм гомумиләштерү;

«Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законның 5 статьясында каралган затлар саны турында мәгълүмат җыю һәм гомумиләштерү, аларга карата балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре тарафыннан индивидуаль профилактик эш алып барыла;

ситуацияне анализлау максатында муниципаль комиссиягә карау өчен балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеге, хокук бозулары, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау турында мәгълүматларны гомумиләштерү;

балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау мәсьәләләре буенча мәгълүмати һәм аналитик материаллар әзерләү;

муниципаль комиссия рәисе йөкләмәсе буенча муниципаль комиссия алдында торган бурычларны хәл итү өчен эксперт төркемнәре, штаблар, шулай ук

консилиумнар һәм башка киңәшмә органнары эшен оештыру;

муниципаль комиссия алдында торган бурычларны хәл итү өчен федераль дәүләт органнары, федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм башка берләшмәләр, оешмалар белән хезмәттәшлекне гамәлгә ашыру;

федераль дәүләт органнарына, федераль дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга, муниципаль комиссияләргә муниципаль комиссия утырышында карау өчен кирәкле материаллар (мәгълүмат) тапшыру турында соратуларны җибәрү;

муниципаль комиссия эшчәнлеге турындагы мәгълүматка массакүләм мәгълүмат чараларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә публикацияләр һәм чыгышлар әзерләүдә катнашу юлы белән, игъланнары балигъ булмаганнарның, аларның ата-аналарының һәм башка законлы вәкилләренең закон тарафыннан саклана торган хокукларын һәм мәнфәгатьләрен боза торган белешмәләрне публикацияләрдә һәм чыгышларда кулланмыйча, керүне тәэмин итү;

муниципаль комиссия тарафыннан Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча муниципаль комиссия эшчәнлеген тәэмин итү кысаларында башка вәкаләтләрне үтәү;

муниципаль берәмлек территориясендә социаль куркыныч хәлдә булган балигъ булмаганнар саны турында мәгълүмат җыюны, гомумиләштерүне гамәлгә ашыру;

балигъ булмаганнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре буенча норматив хокукый актлар проектларына бәяләмәләр әзерләүдә катнашу;

муниципаль комиссия тарафыннан Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча муниципаль комиссия эшчәнлеген тәэмин итү кысаларында башка вәкаләтләрне үтәү.»;

3.5 пунктка «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында билгеләнгән тәртип һәм сроклар нигезендә карала торган административ хокук бозулар турында эшләрдән тыш» сүзләрен өстәргә;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Муниципаль комиссия утырышлары эш планнары нигезендә айга кимендә ике тапкыр үткәрелә.

Муниципаль комиссиянең эш планы проектына тәкъдимнәр муниципаль комиссиягә аның әгъзалары тарафыннан муниципаль комиссия рәисе яисә муниципаль комиссия карары белән билгеләнгән срокларда язма рәвештә кертелә.

Муниципаль комиссия утырышында мәсьәләләрне карау буенча түбәндәге тәкъдимнәр булырга тиеш:

а) мәсьәләнең исеме һәм аны муниципаль комиссия утырышында карау кирәклеген кыскача нигезләү;

б) мәсьәләне әзерләү өчен җаваплы муниципаль комиссия органы (оешмасы, учреждениесе), һәм (яки) вазыйфаи зат турында мәгълүмат;

в) бергә үтәүчеләр  исемлеге (булганда).

Муниципаль комиссиянең эш планы проектына тәкъдимнәр алдан килештерү өчен муниципаль комиссия әгъзаларына җибәрелә ала.

Муниципаль комиссиянең эш планы проекты муниципаль комиссиягә кергән тәкъдимнәр нигезендә төзелә, муниципаль комиссия рәисе белән килештереп, муниципаль комиссиянең эш планын гамәлгә ашыру елына кадәр утырышта фикер алышу һәм раслау өчен чыгарыла.

Муниципаль комиссиянең эш планына үзгәрешләр аның составына керүче затларның тәкъдимнәре нигезендә муниципаль комиссия утырышында кертелә.

Муниципаль комиссия әгъзалары, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләренең, шулай ук Татарстан Республикасы буенча федераль башкарма хакимият органнарының башка территориаль органнарының, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның вазыйфаи затлары муниципаль комиссия эш планын үтәү йөзеннән муниципаль комиссия утырышларында карау өчен тиешле мәгълүмати материаллар әзерләү йөкләнгән.

Муниципаль комиссия утырышының көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча мәгълүмати материаллар муниципаль комиссиягә органнар (оешмалар), вазыйфаи затлар, муниципаль комиссия әгъзалары тарафыннан, аларны әзерләү өчен җаваплы муниципаль комиссиянең эш планы нигезендә, утырыш уздырылган көнгә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча муниципаль комиссиягә тапшырыла һәм үз эченә ала:

а) карауга чыгарылган мәсьәлә буенча белешмә-аналитик мәгълүмат;

б) карала торган мәсьәлә буенча муниципаль комиссия карары проектына тәкъдимнәр;

в) тәкъдим ителгән муниципаль комиссия карары проекты буенча аерым фикерләр, әгәр андыйлар булса;

г) балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасының кызыксынучы органнары һәм учреждениеләре, башка дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары белән муниципаль комиссия карары проектын килештерү материаллары;

д) мәсьәләне карау өчен кирәкле башка мәгълүматлар.

Материалларны әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән срокта тапшырмаган яки әлеге материалларга карата таләпләрне бозып тапшырган очракта, мәсьәлә караудан төшерелергә яки муниципаль комиссия рәисе карары нигезендә башка утырышка күчерелергә мөмкин.

Утырышның көн тәртибе, утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләр буенча карарлар проектлары һәм әлеге мәсьәләләр буенча тиешле материаллар утырыш уздырылган көнгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча муниципаль комиссия әгъзаларына җибәрелә.

Муниципаль комиссия әгъзалары һәм утырышның көн тәртибе, карар проекты һәм башка материаллар җибәрелгән, искәрмәләр һәм тәкъдимнәр булган очракта аларны утырыш башланганчы муниципаль комиссиягә тапшыралар.»;

3.19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.19. Муниципаль комиссия карарлары ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

Тавышка муниципаль комиссия әгъзаларының бер, ике яки берничә тәкъдиме куелырга мөмкин.

Комиссия әгъзаларының каршылыклары булмаган очракта гына тавыш бирү үткәрелмәскә мөмкин. Бу очракта каршылыклар булмау муниципаль комиссия әгъзаларының карарның тәкъдим ителгән варианты белән ризалыгы буларак кабул ителә.

Карар кабул ителгән дип санала, әгәр аның өчен проголосовало күпчелек аның әгъзалары. Комиссия утырышында рәислек итүче тавышлар саны тигез булган очракта, рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора. Шул ук вакытта рәислек итүче башта тавыш бирмәгән фикерне хупларга хокуклы.

Карала торган материалның (эшнең) үзенчәлеген исәпкә алып, тавыш бирү материал (эш) карала торган затның, шулай ук материалны (эшне) карауда катнашучы башка затларның барында да, шулай ук аның янында да үткәрелергә мөмкин.

Муниципаль комиссия рәисе тарафыннан игълан ителгән тавыш бирү нәтиҗәләре муниципаль комиссия утырышы беркетмәсенә кертелә.

Муниципаль комиссия әгъзасы, муниципаль комиссия карары белән килешмичә, муниципаль комиссия утырышы беркетмәсенә мәҗбүри кушылырга тиешле үзенең аерым фикерен язма рәвештә бәян итәргә хокуклы.»;

3.22 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.22. Муниципаль комиссия утырышы беркетмәсе муниципаль комиссиянең һәр утырышында алып барыла һәм түбәндәге мәҗбүри нигезләмәләрне үз эченә ала:

муниципаль комиссия утырышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

муниципаль комиссия исеме;

көн тәртибе;

утырышта катнашучылар һәм муниципаль комиссия әгъзалары, утырышта катнашучы башка затлар турында белешмәләр;

муниципаль комиссия утырышын документлаштыру ысулы турында билге (стенография, видеоконференция, диктофонга язылу һ. .));

муниципаль комиссия утырышында каралган мәсьәләләрнең исеме һәм аларны тикшерү барышы;

карала торган административ хокук бозу вакыйгасы турында белешмәләр, карала торган материалларны (эшләрне) карап тоту);

фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), туу датасы һәм урыны, яшәү урыны һәм материаллар (эшләр) карап тикшерү өчен әһәмиятле булган башка затлар турында белешмәләр (эшләр) аларга карата материаллар (эшләр) карала;

административ эшне карауда катнашучы һәм утырышта булмаган затларга билгеләнгән тәртиптә хәбәр итү турында белешмәләр;

утырышта катнашучы затларның хокукларын һәм бурычларын аңлату турында белешмәләр;

утырышта катнашучы тиешле затларның аңлатмалары, күрсәтмәләре, аңлатмалары һәм бәяләмәләре;

утырышта игълан ителгән отводлар, үтенечнамәләр һәм аларны карау нәтиҗәләре турында белешмәләр;

экспертлар бәяләмәләре турында белешмәләр;

материаллар (эшләр) караганда тикшерелгән документлар турында белешмәләр);

муниципаль комиссия утырышында карала торган мәсьәләләр буенча тавыш бирү нәтиҗәләре;

каралган мәсьәләләр буенча кабул ителгән карар;

кабул ителгән карарларны игълан итү турында белешмәләр;

кабул ителгән карарларга шикаять бирү срокларын һәм тәртибен аңлату турында белешмәләр.

Муниципаль комиссия утырышы беркетмәсенә муниципаль комиссия утырышында рәислек итүче һәм җаваплы секретарь кул куя.

Муниципаль комиссия утырышы беркетмәсенә муниципаль комиссия утырышында каралган мәсьәләләр буенча докладлар материаллары, белешмә-аналитик һәм башка мәгълүмат (булганда) теркәлә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин